ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

29.03.2022　　　　с. Верхний Услон　　　　323

Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының “Югары Ослан
авыл җирлегенең 2030 елга кадәр су
белән тәэмин итү һәм су чыгару схемасын
раслау турында” 2015 елның 26
июнендәге 914 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында, РФ Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең һәм шәһәр округларының коммуналь инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2013 елның 14 июнендәге 502 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемалары турында» 2013 елның 5 сентябрендәге 782 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемаларын эшләү һәм раслау кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлегенең 2030 елга кадәрге су белән тәэмин итү һәм су чыгару схемасын кушымта итеп бирелгән яңа редакциядә расларга.
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, элемтә һәм энергетика буенча йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы　　　　　　　　М.М. Черменский

Әзерләде һәм бастырды:
Макарова А. И. 3 нөсхәдә.